ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2021 Олы Кайбыч ав. №75

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 28 декабрендәге 358 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 25 статьяларына һәм муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 18 июлендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 28 декабрендәге 358 номерлы карарына (2017 елның 7 сентябрендәге 332 номерлы, 2018 елның 20 апрелендәге 132 номерлы, 2021 елның 29 гыйнварындагы 35 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Әгәр алар авыл җирлегендә урнашкан мәдәният учреждениеләрендә 10 елдан да ким эшләмәсәләр һәм Кайбыч муниципаль районында яшәсәләр, мәдәният хезмәткәрләренә, шулай ук пенсиягә чыккан хезмәткәрләргә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен торак мәйданының Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән социаль нормасы һәм коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары чикләрендә түләү чыгымнарының 100%ы күләмендә субсидияләрне билгеләргә».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров